**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 № 1346

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында " 2024 елның 07 октябрендәге 03-12/7086 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карары белән расланган “Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында”гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Нурлат муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль

хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) вазыйфаи окладлары" түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 31 500 |
| Бүлек башлыгы | 27 700 | 27 700 |
| Әйдәп-баручы бухгалтер | 25 300 | 25 300 |
| Бухгалтер | 24 000 | 24 000 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорына һәм муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә. К. Габдуллин